Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**24.11.2021 ел** **№55а**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның планлы чорына бюджеты турында» карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Сарман муниципаль районының 2022 нче елга һәм 2023 һәм 2024 нче елларның планлы чорына «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» Карары проектын беренче укылышта кабул итәргә (1 кушымта).

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында» карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзүне түбәндәге составта расларга:

1. Ибәтуллин И.К – - төркем җитәкчесе;
2. Галлямов И.Ф. - төркем әгъзасы;
3) Кошкина Г.А – төркем әгъзасы;
4) Хаҗиев Р.Р.  - төркем әгъзасы;

5) Сафиуллин А.М. - төркем әгъзасы;

4. Карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеменә җибәрелә, Ф.И.О., авторның туган елы, адресы күрсәтелгән булырга тиеш, ТР, Сарман районы, Җәлил шәһәр тибындагы поселогы, Әхмәдиев ур., 26 йорт адресы буенча, тел. (85559) 31097.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Сарман муниципаль районының 2022 нче елга һәм 2023 һәм 2024 нче елларның планлы чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар 10.12.2021 ел 11.00 сәгатькә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы каравына 07.12.2021 елга кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны текстны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе — Р.Ә.Кәримов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1021601312501
Совет поселка городского типа Джалиль
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы
ИНН 1636001410